**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 декабрь № 977

г. Казань

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен һәм Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 12 статьяга һәм икенче өлешендәге 30 бүлеккә үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 2 ноябрь, ФЗ-307 нче Федераль закон, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-49 нчы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен;

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәне.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм

бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 22 август, 407 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 22 декабрь, 912 нче; 2010 ел, 19 июль, 577 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 февраль, 88 нче; 2012 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 21 март, 196 нчы; 2013 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2013 ел, 28 июнь, 446 нчы; 2013 ел, 29 август, 612 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 1 март, 133 нче; 2014 ел, 18 апрель, 255 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 742 нче; 2015 ел, 22 гыйнвар, 28 нче; 2015 ел, 9 февраль, 72 нче; 2015 ел, 6 июль, 490 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 269 нчы; 2016 ел, 9 июнь, 382 нче; 2016 ел, 12 октябрь, 737 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.101 пунктча өстәргә:

«3.3.101. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртип нигезендә салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгели.».

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү буенча чаралар оештыруда һәм үткәрүдә булышлык күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\977.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 23 декабрь, 977 нче карары белән расланды

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-49 нчы Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясында күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларыннан (алга таба – биналар (төзелмәләр, корылмалар) һәм бүлмәләр) фактта файдалану төрен билгеләү эшчәнлеген регламентлаштыра.

2. Биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү буенча оештыру эшен Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан төзелгән биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия (алга таба – Комиссия) башкара.

3. Биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү аларны тикшерүне үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне тикшерүне (алга таба – чаралар) үткәрү максатларында, Комиссия карары белән территориясендә «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-49 нчы Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясы нигезендә аларга карата салым базасы аларның кадастр кыйммәте буларак билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан һәр торак пунктта биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) формалаштырыла.

5. Эшче төркем формалаштыру турында Комиссия карарында тикшерү үткәрелергә тиешле биналар (төзелмәләр, корылмалар) һәм бүлмәләр исемлеге күрсәтелә, шулай ук аны үткәрү вакытлары билгеләнә.

6. Эшче төркем формалаштыру турында Комиссия карары, аны раслаган көннән соң 3 эш көне эчендә, ләкин тикшерү үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында www.mzio.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырыла.

Эшче төркем формалаштыру турында Комиссия карарының күчермәсе аларга карата тикшерү үткәрелә торган биналар (төзелмәләр, корылмалар) һәм бүлмәләр милекчеләренә (хокук ияләренә) аларның таләбе буенча бирелә.

7. Эшче төркем биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне тикшерүне үткәрүне эшче төркем формалаштыру турында Комиссия карары белән билгеләнгән вакытта гамәлгә ашыра.

Тикшерү вакытында эшче төркем әгъзаларының баруы һәм биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне турыдан-туры карап тикшерү үткәрелә.

8. Тикшерү үткәрү максатларында, эшче төркем күчемсез мөлкәт дәүләт кадастрында, Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында, техник исәпкә алу (инвентарьлаштыру) документларында һәм башка документларда булган мәгълүматтан, ә 2017 елның 1 гыйнварыннан «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 ел, 13 июль, ФЗ-218 нче Федераль закон нигезендә күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрында, техник исәпкә алу (инвентарьлаштыру) документларында һәм башка документларда булган мәгълүматтан файдалана.

9. Эшче төркем әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

аларга карата тикшерү үткәрелә торган биналарга (төзелмәләр, корылмалар) һәм бүлмәләргә барырга;

биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү максатларында, биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне үлчәүне үткәрергә һәм башка гамәлләр башкарырга.

10. Тикшерү барышында Комиссиягә тәкъдим ителә торган биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалануны терки торган фотога һәм (яки) видеога төшерү гамәлгә ашырыла.

11. Тикшерү нәтиҗәләре буенча эшче төркем тикшерү үткәргән көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча Бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне тикшерү акты (алга таба – тикшерү акты) төзи һәм Комиссиягә тапшыра.

12. Тикшерү үткәргәндә эшче төркемгә тикшерелергә тиешле бинага (төзелмәгә, корылмага) һәм бүлмәгә керергә комачаулый торган хәлләр килеп чыккан очракта һәм шул ук вакытта әлеге бинаны (төзелмә, корылма) һәм бүлмәне сәүдә объектлары урнаштыру өчен файдалануны дәлилли торган билгеләр булса, тикшерү акты ачыкланган билгеләрне һәм эшче төркемгә бинага (төзелмәгә, корылмага) һәм бүлмәгә керергә комачаулый торган хәлләрне күрсәтеп рәсмиләштерелә.

13. Комиссия 5 эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 10 нчы пункты нигезендә тапшырылган тикшерү актын карый һәм карарга кул куелган көннән соң 3 эш көне эчендә Министрлыкка бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләү буенча тәкъдимне үз эченә алган карарны тапшыра.

14. Министрлык Комиссия карарын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кертелгән көннән соң 5 эш көне эчендә бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләү турында боерык чыгара.

15. Министрлыкның бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләү турындагы боерыгы Министрлыкның рәсми сайтында боерык чыккан көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

Министрлыкның бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләү турында боерыгы күчермәсе, боерык чыккан көннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, бина (төзелмә, корылма) һәм бүлмә милекчесенә адресы буенча тапшыру хакында хәбәрнамә белән заказлы хат аша җибәрелә яисә

бина (төзелмә, корылма) һәм бүлмә милекчесенә яки аның вәкиленә кул куйдырып тапшырыла.

16. Министрлыкның боерыгында күрсәтелгән бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төре белән риза булмаган очракта, бина (төзелмә, корылма) һәм бүлмә милекчесе Министрлыкка, ризасызлык сәбәпләрен күрсәтеп, язма мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

Бина (төзелмә, корылма) һәм бүлмә милекчесе Министрлык билгеләгән фактта файдалану төреннән аерылып торган башка бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен раслый торган документлар, фото- һәм (яки) видеоматериаллар тапшырырга хокуклы.

17. Министрлык әлеге Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне Комиссия утырышында карап тикшерүне һәм мөрәҗәгать кертелгән көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә җавап җибәрүне тәэмин итә.

18. Мөрәҗәгатьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Министрлык боерыгында күрсәтелгән фактта файдалану төреннән аерылып торган башка бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләүне Министрлыкка тәкъдим итәргә;

б) үткәрү вакытын күрсәтеп, бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне кабат тикшерүне үткәрергә;

в) Министрлыкка бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен үзгәрешсез калдырырга тәкъдим итәргә.

19. Әлеге Тәртипнең 18 нче пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән Комиссия карарын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, Министрлык әлеге карар кертелгән көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү турында боерыкка тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итә һәм әлеге мәгълүматны бу Тәртипнең 15 нче пунктында күрсәтелгән вакыт аралыгында Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыра.

20. Әлеге Тәртипнең 18 нче пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән Комиссия карары нигезендә эшче төркем бу Тәртипнең 7-11 нче пунктлары нигезендә Комиссия карарында күрсәтелгән вакыт аралыгында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне кабат тикшерүне үткәрә.

21. Биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне кабат тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия әлеге Тәртипнең 17 нче пунктындагы «а» яки «в» пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул итә, һәм ул Министрлыкка бу Тәртипнең 13 нче пункты нигезендә тапшырыла.

---

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү тәртибенә кушымта

Бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне
ТИКШЕРҮ АКТЫ

20__ елның "___" ____________ ________________________________
(торак пункт исеме)

| |
|---|
| |
| (техник һәм кадастр паспорты нигезендә объектның исеме) |
| Объектның адресы (урнашкан урыны) |
| Россия Федерациясе субъекты: |
| Шәһәр, поселок, авыл: |
| Урам (тыкрык): |
| Йорт: |
| Корпус: |
| Төзелмә: |
| Объектның милекчесе (тулы исеме, ИНН): |

1. Гомуми мәгълүматлар

| 1.1. Бина (төзелмә, корылма), бүлмә турында гомуми мәгълүматлар | |
|---|---|
| Кадастр саны | |
| Гомуми мәйданы (кв.метр) | |
| Катлар саны | |
| Билгеләнеше | |
| 1.2. Җир кишәрлеге турында гомуми мәгълүматлар | |
| Кадастр саны | |

| | |
|---|---|
| Рөхсәт ителгән файдалану | |
| Гомуми мәйданы (кв.метр) | |

2. Урыннарны фактта файдалану тасвирламасы

| Т/с | Урын исеме | Мәйданы (кв.метр) | Фактта файдалану |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

3. Фактта файдалану турында бәяләмә

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_____________________________________________

Эшче төркем әгъзалары:

______________________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), вазыйфасы) (имза)

_____________________________________

F:\KARAR\2016\977_2.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 23 декабрь, 977 нче
карары белән расланды

Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны)
һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен
карап тикшерү буенча комиссия турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссиянең (алга таба – Комиссия) төп бурычларын, вәкаләтләрен һәм эшчәнлек тәртибен билгели.

2. Комиссия салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү өчен төзелә.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Салым кодексы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Комиссия рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдән һәм башка Комиссия әгъзаларыннан тора.

Комиссия рәисе Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия утырышының көнен билгели һәм көн тәртибен раслый, Комиссия утырышларында рәислек итә, тиешле документларны имзалый.

Комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

Комиссия секретаре Комиссия эшен тәэмин итә, шул исәптән Комиссия әгъзаларына утырышларның көне һәм вакыты турында хәбәр итә, Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча эш башкаруны алып бара, материалларны саклауны һәм алга таба архивка тапшыруны тәэмин итә, Комиссиянең эш тәртибе буенча консультация бирә.

5. Комиссия составында кимендә 5 кеше булырга тиеш.

Комиссия составына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча), Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча) вәкилләре, башка затлар кертелә.

6. Комиссия түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

6.1. Салым салу максатларында биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләүгә кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерә.

6.2. Территориясендә «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 ел, 28 ноябрь, ТРЗ-49 нчы Татарстан Республикасы Законының 1.1 статьясы нигезендә аларга карата салым базасы аларның кадастр кыйммәте буларак билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан һәр торак пунктта биналарны (төзелмәләрне, корылмаларны) һәм бүлмәләрне фактта файдалану төрен билгеләү буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) формалаштыру турында карар кабул итә.

6.3. Эшче төркемнәргә биналарга (төзелмәләргә, корылмаларга) һәм бүлмәләргә кабат тикшерү үткәрүне йөкли.

6.4. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан, юридик һәм физик затлардан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә соратып ала.

6.5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бинаны (төзелмәне, корылманы) һәм бүлмәне фактта файдалану төрен билгеләү буенча тәкъдимне үз эченә алган карарны тапшыра.

6.6. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча үзара хезмәттәшлек итә.

7. Комиссия эшчәнлеге тәртибе:

7.1. Комиссия үз эшчәнлеген утырышлар формасында гамәлгә ашыра.

7.2. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы санала.

7.3. Комиссия утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары саныннан тавышларның гади күпчелеге нигезендә карарлар кабул итә. Тавышлар тигез булган очракта Комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч була.

7.4. Комиссия карарлары Комиссия утырышы беркетмәсе белән раслана.

7.5. Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия рәисе тарафыннан 3 эш көне эчендә имзалана.

7.6. Кабул ителгән карар белән риза булмаган Комиссия әгъзалары үз фикерләрен язма рәвештә белдерергә хокуклы, һәм ул кабул ителгән карарга теркәлә.

7.7. Комиссия карарлары (Комиссия утырышы беркетмәсе күчермәләре яки аннан өземтәләр) кул куелганнан соң 3 эш көне эчендә Комиссия әгъзаларына җибәрелә.

7.8. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документлар белән тәэмин итүне Комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

---